**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Теләче районының аерым территориясендә йогышлылыгы югары булган кош гриппы белән чирләү һәм аның таралу куркынычы янау белән бәйле рәвештә, аның иминлексезлеге сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында**

Кошларның йогышлылыгы югары булган кош гриппы белән чирләү очрагы ачыклану һәм аның таралу куркынычы янау белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының 3[1], 17 статьялары, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 2006 елның 27 мартындагы 90 номерлы карары нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Теләче районы Петровский поселогының Державин урамындагы 17 номерлы шәхси хуҗалык территориясендә йогышлылыгы югары булган кош гриппы буенча, аларны бетерү турында карар кабул ителгәнгә кадәр, чикләү чараларын (карантин) кертергә.

2. Татарстан Республикасының әлеге Указның 1 пункты нигезендә билгеләнгән аерым территориясендә кош, кошчылык продуктларын, азык һәм азыкка өстәмәләрнең әйләнешенә чикләүләр исемлеген, аларны бетерү турында карар кабул ителгәнгә кадәр, расларга.

3. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

а) Татарстан Республикасының әлеге Указның 1 пункты нигезендә билгеләнгән аерым территориясе чикләрендә (алга таба – имин булмаган пункт) эпизоотия чыганагын;

б) имин булмаган пункт чикләреннән 5 км радиустагы территория чикләрендә, Татарстан Республикасы Теләче районының Петровский поселогын, Алга авылын, Пановая Гора авылын кертеп, куркыныч янау зонасын;

в) имин булмаган пункт чикләреннән 10 км радиустагы территория чикләрендә, Татарстан Республикасы Теләче районының Шармаш авылын, Сауш авылын, Баландыш авылын, Айдар авылын, Олы Тиләҗе авылын, Иске Җөри авылын, Караширмә авылын, Үзәк поселогын, Урта Мишә авылын, Тәмте авылын, Карабаян авылын, Олы Нырсы авылын, Субаш авылын, Кече Мирәтәк авылын, Ключище авылын, Яңа Җөри авылын, Алан Җөри авылын,

Иске Карабаян авылын, Кече Нырсы авылын һәм Татарстан Республикасы Саба районының Мамалай авылын кертеп, күзәтү зонасын.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә йогышлылыгы югары булган кош гриппы чыганагын бетерү һәм авыру чыганагының Татарстан Республикасы территориясендә таралуын булдырмау буенча чаралар планын эшләргә һәм расларга.

5. Әлеге Указның үтәлешенә контрольне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2017 ел, 07 июнь
№ ПУ-479

Татарстан Республикасы
Президентының
2017 елның «07» июнендәге
ПУ-479 номерлы Указына
кушымта

**Татарстан Республикасының аерым территориясендә кош, кошчылык продуктлары, азык һәм азыкка өстәмәләр әйләнешенә чикләүләр исемлеге**

Чикләү чаралары (карантин) гамәле вакытында имин булмаган пункт территориясендә:

территориягә чит кешеләр керүне һәм транспорт керүне туктатырга;

турыдан-туры хезмәт күрсәтүче персоналдан һәм чаралар уздырыла торган вакытка өстәмә рәвештә беркетелгән ветеринария өлкәсендәге хезмәткәрләр һәм белгечләрдән тыш чит кешеләр керүне тыярга;

кошларның иминлексез төркеменә хезмәт күрсәтүче персоналның территория буйлап йөрүен чикләргә, аларның башка кошлар һәм аларга хезмәт күрсәтүче затлар белән аралашуын булдырмаска;

чир йоктырган кошларны кан чыгармыйча юк итүне, үлгән һәм юк ителгән кошларны герметик тарага җыюны оештырырга;

кан чыгармыйча массачыл төстә кошларны юк итү вакытында, авыру тудыручы дип күздә тотылган чыганакның әйләнә-тирә мохиттә таралуын булдырмау шартларында, үләксәләрне күмүне билгеләнгән тәртиптә уздырырга;

эпизоотия чыганагы эчендә кошларны күчерүне һәм аннан кошларны, йомыркаларны һәм башка кошчылык продуктларын, шулай ук кош азыгы, эш коралларын, җиһазларны, кош тизәген чыгаруны туктатырга;

кош-корт асрый торган башка йорт биләмәләренә керүне тыярга, кошларны һәм аннан алынган продуктларны, эш коралларын, җиһазларны, кош тизәген чыгаруны туктатырга;

эпизоотия чыганагы чикләреннән кошларны чыгаруны һәм аларны башкача файдалануны туктатырга;

кошлар сатуны вакытлыча туктатырга;

имин булмаган пунктка илтүче барлык юлларны (сукмакларны) ябарга, кирәкле санда дезинфекцияләү киртәләре, кием-салымны эшкәртү өчен пароформалин камералары һәм дезинфекцияләү җайланмалары белән җиһазландырылган тәүлек әйләнәсе кизү торачак контроль-үткәрү постлары куярга, аларда эшләргә ветеринария инспекторларын һәм хокук саклау органнары хезмәткәрләрен җәлеп итәргә;

карантин зонасында транспорт хәрәкәтен чикләргә, шул исәптән керү рөхсәт ителгән транспорт карантин зонасына кергәндә һәм аннан чыкканда мәҗбүри дезинфекцияләнергә тиеш;

авыруларга аеруча бирешүчән баш санын сую һәм юкка чыгару буенча чаралар уздырырга.